**СОВЕТ СОКУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422622 с.Сокуры,
ул. Школьная, д.1
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКУРЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422622 Сокуры авылы,
Школьная урамы, 1 а нчы йорт,
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

2023 елның 31 октябре 54 номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегендә (Обухово торак пункты территориясендә Спартаковская, Төзелеш, Бакча урамнары) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегендә (Обухово торак пункты территориясендә Спартаковская, Төзелеш, Бакча урамнары) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Гражданнар җыенын үткәрү датасы һәм вакыты - 2023 елның 12 ноябрендә 15. 00 сәгатьтә;

2.2. Үткәрү урыны (гражданнарны җыю) - Обухово авылының Спартаковская урамындагы 4 нче йорт янында (Спартаковская, Төзелеш, Бакча урамнарында яшәүчеләр өчен)..

3. Муниципаль район Сокуры торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан тыш, 2024 елда 5000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллауга сез ризамы:

- Обухово авылында урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту, атап әйткәндә, юл япмасын вак ташлау (смета буенча юлны ремонтлау: вак

таш, ком сатып алу, нигез әзерләү, китерү, салу, килешү буенча эш өчен түләү)..

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Сокуры**
**авыл җирлеге Советы рәисе :** **Р.Н.Газизуллин**